КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 август г.Казань № 616

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү турында» 2015 ел, 2 апрель, 214 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү турында» 2015 ел, 2 апрель, 214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 май, 343 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары белән тәэмин итү гражданнарның түбәндәге категорияләренә гамәлгә ашырыла:

60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты хакында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына;

60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), пенсияләрне әлеге пунктның икенче абзацында каралганнан башка нигезләр буенча алучы яисә эш (хезмәт) өчен гомерлек түләү алучы хезмәт ветераннарына, әгәр аларның уртача айлык керем күләме 20 000 сумнан артмаса;

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр чорда, СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорыннан тыш, тылда кимендә алты ай эшләгән затларга, Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән затларга;

акланган гражданнарга;

сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнарга;

60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затларга;

60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), картлык буенча яисә башка нигезләр буенча пенсия алучы йә эш (хезмәт) өчен гомерлек матди ярдәм алучы тиешле стажы булган картлык буенча яисә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алучы «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган затларга.

Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләүсез теш протезлау һәм түләүсез колак протезлары алу хокукына ия аерым категориядәге гражданнар регистрын (алга таба - региональ регистр) алып бару Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

6 пунктта «(колак протезлары)» сүзләрен «түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта:

сигезенче абзацта «тиешле елга» сүзләреннән соң «һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «теш протезлары һәм колак протезлары» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта:

өченче абзацта «теш протезлары һәм колак протезлары» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «теш протезлары һәм колак протезлары» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Әлеге Тәртипнең 3 пунктының беренче - сигезенче абзацларында күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан

Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы бюджетының әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә бирелә торган акчаларының төп бүлүчесе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша тотыла.

Бюджетара трансфертларны тоту Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 3 пунктының беренче - сигезенче абзацларында күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре чикләрендә соңгысы бюджет заявкалары алган көннән алып биш эш көне эчендә һәм бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары чикләрендә бюджетара трансфертлар бирә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы әлеге Тәртипнең 3 пунктының беренче - алтынчы абзацларында күрсәтелгән максатлар өчен иң чик финанслау күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.»;

13 пунктта:

икенче абзацта «теш протезлары (колак протезлары)» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына трансфертлар керү һәм алдагы чорда билгеләнгән йөкләмә күләмнәрен үтәү шарты белән медицина оешмаларын агымдагы айның 20 числосына кадәр түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары буенча хезмәт күрсәтүләрнең планлы күләменең айлык бәясе 30 процент күләмендә авanслау (декабрьдә - 95 процент).;»;

дүртенче абзацта «теш протезлары (колак протезлары)» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «теш протезлары (колак протезлары)» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «теш протезлары (колак протезлары)» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә форма буенча бюджет заявкасы бирү.»;

15 пунктта «теш протезлары һәм колак протезлары» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта «теш протезлары һәм колак протезлары» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $16^1$ – $16^3$ нчы пунктлар өстәргә:

«$16^1$. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан файдаланылмаган бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Бу Тәртип нигезендә алынган акчаның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карарны, күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы кабул итә.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карар нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган Фонд бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен бирелгән Фонд бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

162. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды Татарстан Республикасы бюджетының бирелгән акчаларын медицина оешмалары тарафыннан түбәндәге очракларда өлешчә яисә тулысынча кире кайтаруны тәэмин итәләр:

әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда (кимегәндә);

медицина оешмалары тарафыннан акча максатчан файдаланылмаганда.

163. Әлеге Тәртипнең 162 пунктында күрсәтелгән очракларда медицина оешмаларына бирелгән акчалар Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты кеременә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының тиешле таләбе алынган көннән 15 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмасы тарафыннан акчаны кире кайтару сроклары бозылганда Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән 30 көн эчендә акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды әлеге Тәртипнең 162 пунктында каралган нигезләр буенча медицина оешмаларыннан кергән акчаларны Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина

иминияте фонды счетына күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсендә ачылган көннән алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keремeнә кайтара.»;

17 пунктта «теш протезлары һәм колак протезлары» сүзләрен «түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү тәртибенә 5 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 2 август, 616 нчы карары редакциясендә)

Форма

20______ елга Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак протезлары буенча хезмәтләр күрсәтү программасын финанслауга бюджет гаризасы

(сум)

| Гражданнар категорияләре исемнәре | ____ елга план | Хисап чорына план күләме | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды счетына акчалар керде | Агымдагы айда хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә акчаларның хисап күләме | Бирелгән счетлар реестрларының факттагы күләме | _________ счетлар реестры түләнде | Акчага ихтыяҗ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | гр.5 = гр.3 – гр.4 | 6 | 7 | 8 |
| Барлыгы | | | | | | | |
| 60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты хакында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, уртача айлык керемнәре | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | гр.5 = гр.3 – гр.4 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннары; 60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), пенсияләрне әлеге пунктның икенче абзацында каралганнан башка нигезләр буенча алучы яисә эш (хезмәт) өчен гомерлек түләү алучы хезмәт ветераннарына, әгәр аларның уртача айлык керем күләме 20 000 сумнан артмаса | | | | | | | |
| 1941 елның 22 июненнән алып 1945 елның 9 маена кадәр чорда тылда кимендә алты ай, СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорыннан тыш, эшләгән затлар; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар | | | | | | | |
| Акланган гражданнар | | | | | | | |
| Сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнар | | | | | | | |
| 60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | гр.5 = гр.3 – гр.4 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар;<br>60 һәм 55 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), картлык буенча яисә башка нигезләр буенча пенсия алучы йә эш (хезмәт) өчен гомерлек матди ярдәм алучы тиешле стажы булган картлык буенча яисә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алучы «Татарстан Республикасы дәүләт бүләк-ләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләк-ләренә лаек булган затлар | | | | | | | |

Директор ______________ /____________________________________/
(имза) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Башкаручы ____________________________________ ______________ /____________________________________/
(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.

______________________________